**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 февраль № 91

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданлык билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләренең дәүләт исәбен алу һәм саклау буенча бердәм система турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2010 ел, 12 март, 133 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 31 декабрь, 1188 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән берлектә, агымдагы финанс елында Системада теркәлергә һәм исәпкә алынырга тиешле гражданлык әһәмиятендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр исемлеген (алга таба – Исемлек) бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә ел саен төзергә һәм агымдагы финанс елының 15 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.»;

түбәндәге эчтәлекле 5 нче яңа пункт өстәргә:

«5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына агымдагы финанс елының 15 октябренә кадәр бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә Исемлекне Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына кертергә.»;

әлеге карарга, бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта редакциясендә бәян ителгән «Агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында гражданлык әһәмиятендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләренең дәүләт исәбен алу һәм саклау буенча бердәм системада теркәлергә

һәм исәпкә алынырга тиешле гражданлык әһәмиятендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр исемлеге» кушымтасын өстәргә;

5 – 9 нчы пунктларны шул ук эзлеклелектә 6 – 10 нчы пунктлар дип санарга;

Татарстан Республикасында гражданлык билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләренең дәүләт исәбен алу һәм саклау буенча бердәм система турындагы нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтаны бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта редакциясендә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелешне, проектлау-эзләнү, геологик разведка һәм фәнни-тикшеренү эшләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау турында» 2000 ел, 1 август, 562 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2003 ел, 8 декабрь, 631 нче; 2007 ел, 31 гыйнвар, 30 нчы; 2008 ел, 10 июнь, 385 нче; 2010 ел, 12 март, 133 нче; 2011 ел, 9 февраль, 78 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төзелешне, проектлау-эзләнү, геологик разведка һәм фәнни-тикшеренү эшләрен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау турындагы вакытлыча нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.8 нче пунктның бишенче абзацындагы «максатчан программалар буенча үтәлүче» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\91.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 февраль, 91 нче
карарына 1 нче кушымта

Форма

Агымдагы финанс елында Татарстан Республикасында гражданлык билгеләнешендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләренең дәүләт исәбен алу һәм саклау буенча бердәм дәүләт системасында теркәлергә һәм исәпкә алынырга тиешле гражданлык әһәмиятендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр исемлеге

| Т/с | Эшләр исеме | Эшләрне башкару нигезе | Эшләр башкару өчен нигез булып торучы норматив хокук актлары һәм башка актлар реквизитлары | Агымдагы елда финанслау лимиты, мең сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

F:\KARAR\2015\91-1.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 16 февраль, 91 нче
карарына 2 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасында гражданлык әһәмиятендәге фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык һәм технологик эшләр нәтиҗәләрен исәпкә алу буенча мәгълүмат картасы**

1. Теркәү номеры: ______________________________________________________
(Объектны Система реестрында исәпкә алу номеры
(вәкаләтле оешма тарафыннан куела)

1.2. Эш исеме: ______________________________________________________
______________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы бюджеты акчасын бүлеп бирү өчен нигез булып торган дәүләт контракты яки документлар исеме, датасы һәм номеры)

2. Баш оешма-башкаручы турында мәгълүматлар

2.1. Оешма исеме: ______________________________________________________
2.2. Оешма адресы: ______________________________________________________
2.3. Телефоны/факсы: ______________________________________________________
2.4. Электрон адресы (e-mail): ______________________________________________
2.5. Веб-сайты: ______________________________________________________
2.6. Оешма җитәкчесе: ______________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе, исеме)

2.7. Эш җитәкчесе: ______________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе, исеме)

3. Оешма-башкарышучы (нәтиҗәләрне эшләүче)
турында мәгълүматлар

3.1. Оешма исеме: ______________________________________________________
3.2. Оешма адресы: ______________________________________________________
3.3. Телефоны/факсы: ______________________________________________________
3.4. Электрон адресы (e-mail): ______________________________________________
3.5. Веб-сайты: ______________________________________________________
3.6. Оешма җитәкчесе: ______________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе, исеме)

3.7. Эш җитәкчесе: ___________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы, гыйльми дәрәҗәсе, исеме)

## 4. Фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүматлар

4.1. Патент тикшеренүләре турында хисап: ________________________________________
(үткәрелүен яки үткәрелмәвен күрсәтергә)

4.2. Фәнни-техник эшчәнлектән алынган нәтиҗәләр турында мәгълүматлар: ___________________________________________________________________________

4.2.1. Нәтиҗә (нәтиҗәләр) исеме: ____________________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.2. Нәтиҗәнең кыскача тасвирнамәсе: _______________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.3. Нәтиҗәне куллану техникасы өлкәсе: ____________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.4. Нәтиҗәне куллану техникасы объекты: ___________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.5. Нәтиҗәне куллану техникасы объектының тормыш циклы этабы____________
___________________________________________________________________________

4.2.6. Нәтиҗәне техник камилләштерү юнәлеше: _____________________________
___________________________________________________________________________

4.2.7. Нәтиҗә турында мәгълүматлар кертү формасы: __________________________
___________________________________________________________________________

4.2.8. Нәтиҗәне куллануның перспективалы юнәлешләре: _______________________
___________________________________________________________________________

4.2.9. Нәтиҗә турында мәгълүматларны үз эченә алган документлар исемлеге: ___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.10. Документлар иясенең исеме: __________________________________________
___________________________________________________________________________

4.2.11. Документларның контрольдәге нөсхәсен тотучы исеме: _________________
___________________________________________________________________________

4.3. Интеллектуаль милекнең патент алырга тәкъдим ителгән объектлары турында мәгълүматлар:
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

4.3.1. Интеллектуаль милек объектының төре: _______________________________
___________________________________________________________________________

4.3.2. Сәнәгать милке объекты исеме (автор хокукы объекты исеме): _____________
___________________________________________________________________________

4.3.3. Саклау документы номеры: ____________________________________________
___________________________________________________________________________

4.3.4. Башка хокук ияләре: _________________________________________________

4.3.5. Өстенлек: ____________________________________________________________
4.3.6. Авторлар: ____________________________________________________________
4.3.7. Халыкара классификация индексы (МПК, МКПО, МКТУ): _________________
____________________________________________________________________________

4.4. Фәнни-техник эшчәнлекнең патент алырга потенциаль сәләтле нәтиҗәләре турында мәгълүматлар: _______________________________________________________
4.4.1. Нәтиҗәнең исеме: ______________________________________________________
4.4.2. Роспатентның саклау документын бирүгә гариза номеры (булганда): ____________________________________________________________________________

4.5. Фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләренә хокук турында мәгълүматлар: __________
____________________________________________________________________________

| | |
|---|---|
| Оешма – дәүләт заказчысы җитәкчесе | Вәкаләтле оешма җитәкчесе |
| ____________________________ | ______________________________ |
| Имзасы ___________________________ | Имзасы ___________________________ |
| Дата ____________________________ | Дата ____________________________ |
| М.У. | М.У. |

____________________________________